# КАРАР

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Күпербаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2022 елның 30 ноябре** **N 5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 14 ноябреннән 28 ноябренә кадәр түбәндәге мәсьәлә буенча уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Арча муниципаль районы Күпербаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын яки ирен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- Материаллар сатып алып, Күпербаш авылында чишмә яны территориясен торгызу?

«Әйе» «Каршы»

Гражданнар җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 321 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 173 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 97 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен 76 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Күпербаш авылында гражданнар җыенын узды дип танырга.

2. «Сез 2023 елда Арча муниципаль районы Күпербаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын яки ирен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- Материаллар сатып алып, Күпербаш авылында чишмә яны территориясен торгызу?

«Әйе» «Каршы»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен гражданнар күпләп җыела торган урыннарда ТР, Арча районы, Күпербаш авылы, Мичурин ур., 10 йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы И.Г. Нуриев